ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 442 от «08» 11 2023 г.

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасына өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 мартындагы «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» программасын яңа редакциядә раслау турында» 98 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. В «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасының Паспортында, «Муниципаль программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанс белән тәэмин итү Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан каралган.

Программаны Мамадыш муниципаль районы бюджеты акчаларыннан финанслауның гомуми күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

2 550 000 сум

Шул исәптән еллар буенча гамәлгә ашыру:

2023 ел-850 000 сум.;

2024 ел-850 000 сум.;

2025 ел -850 000 сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына Мамадыш муниципаль районының җирле бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш..».

0000012059

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммункация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Ш.Фатыйховка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов